ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 19 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. **Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыру өчен тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләте**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыру өчен тапшырылган эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә түбәндәге төр социаль түләүләрне башкару буенча Россия Федерациясе вәкаләтен (алга таба – Россия Федерациясе вәкаләте) гамәлгә ашыралар:

1) эшсезлек пособиесе;

2) эшсез гражданга картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган, иминият пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәнчегә кадәрге чорга халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениесе тәкъдиме белән билгеләнгән пенсия;

3) ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга ай саен өстәмә түләү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 25-ТРЗ